МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

04.08.2021 № 256

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 09.01.2014 № 6 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы штат расписаниесе үзгәрүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы ГТХМ дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарны гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының (алда – Татарстан Республикасы ГТХМ) 09.01.2014 № 6 (Татарстан Республикасы ГТХМ 05.05.2014 № 205, 14.12.2015 № 572, 23.05.2016 № 215, 09.04.2019 № 136, 25.06.2020 № 209 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә алдагы үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектәге унбишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

II бүлектәге өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге боерыкны министр урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә һәм Татарстан Республикасы ГТХМ аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Т.В. Кәримуллин